**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 22 август № 579

г. Казань

«Иннополис мәктәбе» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесен төзү турында

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешнең 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Иннополис мәктәбе» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесен (алга таба – гомуми белем бирү учреждениесе) төзү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Россия Федерациясе субъектының Россия Федерациясе законнарында каралган мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү буенча вәкаләтләрен тормышка ашыруны тәэмин итү гомуми белем бирү учреждениесе эшчәнлегенең максаты булып тора;

гомуми белем бирү учреждениесен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы гамәлгә ашыра.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

30 көн эчендә гомуми белем бирү учреждениесенең уставын расларга һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә аны дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә;

30 көн эчендә законнарда каралган бүтән оештыру-хокукый чараларны гамәлгә ашырырга, шул исәптән хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә;

ел саен уставында каралган төп эшчәнлеге нигезендә гомуми белем бирү учреждениесе өчен билгеләнгән тәртиптә дәүләт йөкләмәсен расларга.

4. Гомуми белем бирү учреждениесенең гамәлгә куючысы дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә мөнәсәбәттә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына «2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законының «Торак-коммуналь хуҗалык» бүлегендәге «Торак хуҗалыгы» бүлекчәсендә социаль-мәдәни тармак объектларын кабул итүгә һәм кулланылышка кертүгә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына каралган акча исәбеннән гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына 5 389,6 мең сум акча бүлеп бирергә.

6. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына гомуми белем бирү учреждениесе уставын дәүләт теркәвенә алган көннән соң 30 көн эчендә оператив идарә итү хокукында, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы биргән исемлек нигезендә дәүләт мөлкәтен, шул исәптән аеруча кыйммәтле күчмә мөлкәтне беркетергә.

7. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә әлеге карарның 2 – 6 пунктлары үтәлгәннән соң 60 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга Татарстан Республикасының социомәдәни тармактагы аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарны раслау турында» 2015 ел, 20 ноябрь, 880 нче карарына аны әлеге карарның 1 пунктына яраштыру өлешендә үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын эшләргә һәм аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каравына  кертергә.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков